Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Советы утырышы

КАРАРЫ

6 февраль 2026 ел №11

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 106 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында " 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Күәм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 106 номерлы "Җир салымы турында"гы карарына (20.01.2020 N 121, 30.10.2020 N 7, 30.01.2024 N 92, 24.10.2024 N 106, 29.07.2025 N 132 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә :

**1.1. 4 пунктның 4.3 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

“4.3. Әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса, салым түләүче оешмалар тарафыннан салым узган салым чорыннан соң килүче елның 28 мартыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш, салым буенча аванс түләүләре салым түләүче-оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килүче икенче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш”;

**1.2. 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.4 пунктчасы өстәргә:**

“4.4. Салым (салым буенча аванс түләве) үткән салым (хисап) чорлары өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасын исәпләүгә (кабат исәпләүгә) китерә торган белешмәләр нигезендә исәпләп чыгарылган салым (салым буенча аванс түләве) салым түләүче оешмалар тарафыннан тиешле чор өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасы турында хәбәр төзелгән айдан соң килүче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш».

2. Әлеге карар 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Сәмигуллин Л.Ә.